КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 26 сентябрь г.Казань № 764

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 елга «Физик-математик алгарыш» проектын гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларының 5 – 11 сыйныфларында белем алучыларны акчалата бүләкләү турында» 2025 ел, 12 май, 311 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 елга «Физик-математик алгарыш» проектын гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларының 5 – 11 сыйныфларында белем алучыларны акчалата бүләкләү турында» 2025 ел, 12 май, 311 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган 2025 елга «Физик-математик алгарыш» проектын гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларының 5 – 11 сыйныфларында белем алучыларга акчалата бүләкләү бирү тәртибе турында нигезләмәдә:

14 пунктта:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5 – 6 сыйныфларда белем алучылар – 1 нче урыннан 78 нче урынга кадәр;»;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7 – 8 сыйныфларда белем алучылар – 1 нче урыннан 80 нче урынга кадәр;»;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9 – 11 сыйныфларда белем алучылар – 1 нче урыннан 42 нче урынга кадәр.»;

әлеге карар белән расланган 2025 елга «Физик-математик алгарыш» проектын гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларының 5 – 11 сыйныфларында белем алучыларның акчалата бүләкләү алучылар санын һәм күләмен яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлгән).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 12 май, 311 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 26 сентябрь, 764 нче
карары редакциясендә)

2025 елга «Физик-математик алгарыш» проектын гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларының 5 – 11 сыйныфларында белем алучыларның акчалата бүләкләү алучылар санын һәм күләме

| Т/с | Алучылар категориясе | Алучылар саны, кеше | Бер укучыга акчалата бүләкләү күләме, сум |
|---|---|---|---|
| 1. | Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларының 5 – 6 сыйныфларында белем алучылар | 78 | 57 500 |
| 2. | Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларының 7 – 8 сыйныфларында белем алучылар | 80 | 57 500 |
| 3. | Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларының 9 – 11 сыйныфларында белем алучылар | 42 | 57 500 |

______________________